**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АПАС ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАРЫ

**2019 елның 14 октябре** **№ 211**

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының "Апас шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге Советының 2017 елның 29 декабрендәге 96 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы «Апас шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3. Территориаль зоналар чикләре һәр җир участогының таләпләрен үтәп, бары тик бер территориаль зонага, җир законнары нигезендә чикләре территориаль зоналар чикләрен кисәргә мөмкин булган җир кишәрлегеннән тыш, билгеләнә.»;
9 статьяның 4 пункты үз көчен югалткан дип санарга.
2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының "Апас шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге Уставы белән билгеләнгән тәртип нигезендә Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.
3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Апас шәһәр тибындагы бистәсе Башкарма комитеты җитәкчесе Ф. Ә. Шәрәфетдиновка йөкләргә.

**"Апас шәһәр тибындагы поселогы"**
**Муниципаль берәмлек башлыгы,**
**Апас шәһәр җирлеге Советы Рәисе** **Р. Ф. Хисаметдинов**